№ 9 (1188), 23 февраль 2013 ел



сөю һәм шәфкать багланышын урнаштыра.

«Рум» сүрәсендә бу вәзгыять шушы рәвешле телгә алына:

*“Үзегездән хатыннарны ялрату да, ул хатыннар белән бергә яшәвегез дә, ир белән хатын арасындагы мәхәббәт һәм наз, һичшиксез, Аллаһының кодрәтенә ачык дәлилләрдер. Хактыр ки, бу эшләрдә фикерли белүче кавемнәр өчен гыйбрәтләр бар”*.

Хатын-кыз белән ир арасындагы бу сөю һәм кызыксынудан өйләнешеп оя кору теләге туа. Бу рәвешле “гаилә” дип йөртелгән бик мөһим корылыш барлыкка килә.

Иң гомум мәгънәсе белән гаилә - шәҗәрә һәм никах багланышы белән берләшкән, бер түшәм астында урнашкан кешеләр җәмгыяте. Бу җәһәттән җәмгыятьләрнең нигезе вәзгыятендә. Бер милләтнең барлыгы, хозуры, муллыгы һәм тәртибе - гаиләдәге хозур, муллык һәм тәртипкә бәйле. Чөнки җәмгыятьтә гаиләләр хозурлы булса, муллык һәм тәртип эчендә булса - ул җәмгыять дә хозурлы, мул һәм тәртип эчендә булыр.

Милләтләрнең берлеге, бөтенлеге һәм ныклыгы да милләтне барлыкка китерүче гаиләләрнең бөтенлегенә һәм ныклыгына бәйле. Шушы сәбәп аркасында гаилә учагы ни чаклы нык нигезләр өстендә салынса, җәмгыятьләр дә шул кадәр нык һәм көчле булыр. Шуңа күрә дә милләтләрнең берлеге һәм бөтенлегенең таркалуы - гаиләдәге муллык һәм тәртипнең төрле сәбәпләр аркасында бозылуы белән башлана. Чөнки гаилә шәхесләре арасындагы рухи багланышларның өзелүе - үзенә күрә милләт бөтенлегенең таркалуга таба баруы димәк. Буыннары бозылган, яшьләре милли һәм рухи кыйммәтләрдән читләшкән милләтләрнең таркалу барышына керүе бәхәссез.

Гореф-гадәтләребез, йолаларыбыз иң элек гаиләдә өйрәтелә. Киләчәгебезнең ышанычы булган балаларның беренче өйрәнү урыны - шулай ук гаилә. Гаиләдән алган мәдәниятның эзләрен зиһеннән сөртеп ату җиңел булмый.

Динебез өйләнешүне тәшвик итә, «зина һәм фәхишәлек» дип йөртелгән өйләнгәнлек тышындагы мөнәсәбәтләрне кискен рәвештә тыя. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: *«Яшьләр, арагыздан көче җиткәнегез өйләнсен, чөнки гыйффәтне һәм намусны саклауның, әхлакый тормыш алып баруның иң тәэсирле юлы - никахтыр»,* - дип боера, башка бер хәдисендә исә: *«Никах - минем сөннәтемдер, сөннәтемә карап хәрәкәт итмәүче миннән түгелдер»,* - дип әйтеп, өйләнешүне киңәш итә.

Шәхесләрнең бәхете гаиләнең бәхетенә бәйле булганы кебек, җәмгыятьләрнең хозуры да гәиләләрнең хозурына һәм бәхетенә бәйле. Бәхетле өйләнешүләр төрле зәвыкләргә һәм төрле гадәтләргә уңай итеп карый алучы ике кешенең бергәлеге белән тормышка аша ала.

Хәләл җефетләре арасында какшамас ышаныч һәм эчкерсезлек, самимиятнең булуы да - гаиләнең корылышын көчәйтүче төп факторларның берсе. Ике яклы ышаныч һәм эчкерсезлек булмаган гаиләдә сөю һәм хөрмәт тойгыларының булуы да мөмкин түгел.

Пәйгамбәребез: *«Сез барыгыз да бер көтүче һәм идарәгез астына бирелгәннәрдән җаваплы. Дәүләт башлыгы - милләтеннән, гаилә рәисе - гаилә әгъзаларыннан җаваплы»,* - дип боера.

Бөек Китабыбыз кисәтә: *«Әй, иманлы бәндәләр, утын урынына кешеләр һәм ташлар ягылган җәһәннәмнән үзегезне һәм гаилгезне саклагыз».*

**Рәҗәп КЫЛЫЧ.**
*(“Иман” газетасыннан)*

# Дуслык хокуклары

Дустыгыз үз мохтаҗлыгы турында сөйләгәнче үк матди байлыгыгызны, вакытыгызны, эшләрегезне аның өчен корбан итегез.

Бер кеше үзенең өйләнгән дустының өенә акча сорап барган. Дусты бурычка акча биргән. Ул акчаны алып киткәч, бу кеше күз яше белән елый икән. Хатыны сораган: «Син нигә елыйсың, әллә акча өченме? Акча өчен булса, син мең хәйлә табып, бирми кала идең!..» Ләкин ул болай дигән: «Мин дустымның хәле авыр булуын ул әйтердән алда белмәгәнмен, үзе әйткәч кенә аңлавым өчен елыйм».

Дустыгызның серләрен саклагыз. Аның турында кешеләрнең ачуын китерерлек нәрсәләр сөйләмәгез. Дустың турында сөйләүчене үзегез дә сабырлык белән тыңлагыз. Кешегә мөрәҗәгать иткәндә аның кәефен кырырлык сүзләр әйтмәгез. Дустыгызны кеше алдында хөрмәт итегез, яхшы гамәлләре өчен рәхмәт әйтегез. Үзе югында да дустыгызны үзегезне яклаган кебек яклагыз.

Дустыгызга файдалы киңәшләр бирегез, аның җитешмәгән якларын гафу итегез. Аны битәрләмәгез. Ул ялгыз калганда да, исән чагында да, вафатыннан соң да дога укыгыз. Ул бакый дөньядан киткәч, аның ата-анасы, туганнары турында кайгыртыгыз. Үз борчумәшәкатьләрегезне дустыгыз җилкәсенә салмагыз.

Кәефегез нинди булуга карамастан, дустыгызның кайгысын да, шатлыгын да бүлешегез. Аның белән эчкерсез, ихлас булыгыз. Аны беренче булып сәламләгез, урын тәкъдим итегез. Сөйләшкәндә аны игътибар белән тыңлаганнан соң гына үз фикерегезне әйтегез. Дустыгыз белән шундый мөнәсәбәттә булыгыз: үзегезгә нинди мөгамәлә күрсәтүләрен теләсәгез, аңа да шундый мөнәсәбәт булсын. Аллаһы хакы өчен бер-берегезне яратыгыз һәм ихтирам итегез.

*(“Татар мөселман календаре”ннан)*





# Баланың чәчен алу

Бала тугач, җиденче көнендә аның чәчен алырга (башын кырырга) кирәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: *«Бала туганның җиденче көнендә корбан чалырга, сабыйның чәчен алырга һәм аңа исем кушарга кирәк».*

Хәдисләрдән күренгәнчә, башның башта уң, ә аннары сул ягын кырырга кирәк. Башның бер өлешен кырып, икенче өлешен кырмый калдырырга ярамый. Чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әлеге гамәлне тыйган.

Баланың чәчен корбан (гакыйка корбаны) чалганнан соң алсаң - яхшырак. Күп кенә галимнәр дә нәкъ менә шулай эшләү яклы.

Кызганычка, бүгенге көндә күп кенә мөселманнар әлеге сөннәт гамәл турында онытанлар яисә балаларына зыян китерүдән куркып, чәчләрен алмый калдырып, әлеге йоланы үтәмиләр. Ләкин бу бала сәламәтлеге өчен куркыныч гамәл булса, моны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләре дә эшләмәс иде.

Шулай ук матди хәлегезгә карап, чәч авырлыгы күләмендә көмешләтә яки алтынлата хәер дә бирергә кирәк. Хәсән туганнан соң, Пәйгамбәребез кызы Фатыйма радый-аллаһу ганһәгә болай ди: *«Баланың чәчен ал һәм алынган чәче авырлыгында көмешләтә хәер бир».*

Хәерне шулай ук җиденче көндә дә бирергә була. Әмма бу мәҗбүри түгел, шунлыктан хәер бирүне кичектереп торырга мөмкин.

**Рәзил ВӘЛИЕВ.**
*(“Дин вә йола” газетасыннан)*

# Эшләү, тырышлык, ялкаулык һәм буш вакыт турында

Якты дөньяга килгән һәр җан иясе үз вазифасын җиренә җиткерергә тиеш. Бары тик кешеләр генә түгел, ә тереклекнең дәвамлылыгын тәэмин итүче барлык җан ияләре, үсемлекләр, җәнлекләр, кош-кортлар бу дөньядагы вазифаларын җиренә җиткереп, теге дөньяга күчәләр. Тормышның дәвамы өчен һәрберебез бер-беребезгә бәйле һәм мохтаҗбыз. Яралтылган бар нәрсәнең икенче мәгънәсе һәм әһәмияте бар. Мәсәлән, диңгезләрдә, зур океаннарда 90 процент бер дә ишетмәгән, күрмәгән җан ияләре яши. Аларның барлыкка килү хикмәтен без белмибез. Ләкин белгечләр зур тәртип эчендә аларның, һичшиксез, мәгънәләренең булуын һәм тигезлекне тәэмин итүдә әһәмиятле роль уйнауларын ачыклый. Кайбер җәнлекләр кош-корт һәм җан ияләре белән тукланалар. Янә белгечләр аларны үтергән очракта, тукланган җан ияләре санының артып, эпидемия чыгу куркынычын аңлаталар. Шуны да онытмаска кирәк: агачлар, урманнар безнең үпкәләребез.

Әгәр дә җавапсыз рәвештә аларны юк итәргә тырышсак, сулаган һава сыйфатының түбәнәюен һәм тамырлар җибәргән туфракның җиңел рәвештә аякларыбыз астыннан шуып китәчәген әйтәләр. Кайбер документаль фильмнарда шуны күрәбез: арыслан кебек ерткыч җәнлекләр башка җан ияләрен аулап, алар белән туклана. Һәм иң әһәмиятлесе: моны бары тик ач карыннарын туендыру өчен башкаралар. Ягъни бу җәнлекләр күңел ачмый, алар җанвар да түгел. Шулай яратылганнар алар. Зур җан ияләре кечерәкләре белән туклана. һәркем бу дөньяда үз вазифасын үтәргә тиеш. Бу рәвешле хәрәкәт итмәсә, дөньядагы бурычын җиренә җиткермәгән булыр. Моның өчен туганнан башлап шактый ихтыяҗы булган кеше баласының иң әһәмиятлеләреннән берсе - белем алып өйрәтелүе. һәркемнең кызыксынулары, сәләтләре бар. Кечкенә яшьтән башлап һәркем бу сәләтләрен күрсәтергә һәм аңа карап тормышының юнәлтелүенә ихтыяҗ тоя. Бу мәсьәләдә җаваплылык күбрәк гаиләләр өстенә төшә. Ата-ананың вазифасы бала тудыру белән генә чикләнми. Туган баланы сәламәт итеп үстерү, яхшы тәрбияләү, дине вә милләте өчен файдалы кылу - ата-ананың иң зур вазифаларыннан исәпләнә.

Аллаһы барыбызны да бер-беребезгә амәнәт иткән. Ислам дине буенча бөтен кешелек - бер ата-ананың - атабыз Адәм һәм анабыз Һава балалары. Дөньяда тәннәре төрле төстә, төрле диндә һәм төрле иҗтимагый караштa булган кешеләр яши. Ислам динендә булган кешенең мөселман кардәшләренә һәм шулай ук мөселман булмаган кешеләргә карата булган төрле вазифалары бар. Башка кешеләрнең тормышы да безнеке кебек үк хөрмәтле, кыйммәтле һәм кадерледер. Һәр кешенең бу дөньяда яшәргә хакы бар.

Мөселманлык - тырышлык динедер. Динебезнең әһәмиятле мәсьәләләреннән берсе - тырышлык һәм тырышудыр. Аллаһы Тәгалә тырышуны да гыйбадәтләрнең берсе итеп санаган һәм фарыз кылган. Тырышмаган кешеләр ярлы булып калыр, башка кешеләргә мохтаҗ булып, көчләрен, куәтләрен югалтып, башкаларының кул астына төшәрләр. Мондый кешеләр ул вакытта Аллаһыга каршы гыйбадәтләрен төгәл иттереп үти, балаларын укыта алмаслар, мәдәният һәм мәгърифәттән аерылырлар, надан булып калырлар. Аларның диннәре, иманнары зәгыйфьләнер, дөнья кайгысыннан диннәрен кайгыртырлык хәлләре калмас, алар тормышта авыр хәлгә төшәрләр.

Дөньяга артык бирелеп, ахирәтен оныткан кешеләрнең хәлләре дә моңа охшар. Дин, иман